СОВЕТ ЮРТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЬ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮРТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 3 16.09.2019г

Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүматны бастыру Тәртибен раслау турында

06.10.2003елдагы "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ Федераль законы нигезендә, муниципаль хосусыйлыкта булган объектлар турында мәгълүматны "Интернет" мәгълүмати-коммуникацияле челтәрдә урнаштыру һәм актуальләштерү өлешендә 2018 елның 5 апрелендә Россия Федерациясе Дәүләт Советында узган утырыш нәтиҗәләре буенча (2018 елның 15 маендагы (№ Пр-817ГС) Россия Федерациясе Президенты йөкләмәләре исемлеген гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Кушымта №1 нигезендә, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүматны бастыру Тәртибен расларга.

2. Гамәлдәге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Советының план-бюджет-финанслау даими комиссиясенә йөкләргә.

3. Гамәлдәге карар Татарстан Республикасы "Минзәлә муниципаль район" Муниципаль берәмлегенең **http://menzelinsk.tatar.ru**. рәсми сайтында басылырга тиеш.

Советы рәисе И.Ю.Кадыров

Минзәлә муниципаль районының
Юртау авыл җирлеге Советының
16.09.2019 елдагы №3 Карарына
Кушытма

Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең муниципаль
хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүматны бастыру
Тәртибе

1. Гамәлдәге Тәртип Минзәлә муниципаль районының муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүматны аны алуда кызыксынган билгеле бер даирә затларны аңа керү белән тәэмин итү максталарында, Интернет мәгълумати-коммуникацияле челтәрендә (алга таба – Интернет челтәре) бастыру процедурасын билгели.

2. Минзәлә муниципаль районы сайты (http://menzelinsk/tatar.ru) Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүматны Интернет челтәрендә бастыру өчен Минзәлә муниципаль район сайты булып тора.

3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының финанс-бюджет һәм җир-милек палатасы Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүматны Интернет челтәрендә бастыруга вәкаләтле булып тора.

4. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финанс-бюджет һәм җир-милек палатасы Минзәлә муниципаль районының муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүматны Интернет челтәрендә бастырып чыгаруга вәкаләтле булып тора.

5. Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүмат бастырып чыгарылырга тиеш.

6. Россия Федерациясе законнары нигезендә керү чикләнгән мәгълүмат бастырып чыгарылырга тиеш түгел.

7. Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүмат гамәлдәге Тәртипнең кушымта №1 нигезендә объектлар исемлеге рәвешендә бастырып чыгарыла.

8. Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектларының бастырып чыгарылган исемлеге “online режимында күчемсез милек объектлары буенча белешмәле мәгълүмат” һәм “Ачык кадастр палатасы” Интернет челтәрендә Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәтенең рәсми сайтында мәгълүмати сервислар ярдәмендә күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез милек объектлары турында актуаль мәгълүматларны кызыксынган

затларның алу мөмкинлеге турында белешмәле мәгълүмат белән тулыландырыла.

9. Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында мәгълүматны бастыру Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финанс-бюджет һәм җир-милек палатасында исәпләнә торган мәгълүматлар нигезендә, Минзәлә муниципаль районының муниципаль хосусыйлыгы реестрында башкарыла.
10. Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында бастырылган мәгълүматны актуальләштерүне ярты елга бер тапкыр Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финанс-бюджет һәм җир-милек палатасы башкара.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районы
Юртау авыл җирлегенең
муниципаль хосусыйлыгында булган
милек объектлары турында
мәгълүматны бастыру Тәртибенә
Кушымта 1

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең
муниципаль хосусыйлыгында булган милек объектлары турында
мәгълүмат

| № | Милек атамасы | Урнашкан урыны (адрес) | Мәйданыкв.м. | Максатчан билгеләнеше | Вакытлыча чик куюлар | Чикләүләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |